НАДИР БАҺАВИЕВ:

«3D принтерлар – заманча икътисад өчен бик мөһим машиналар»

> 3

МИЛЛИ ҮРНӘК

Караңгы дип зарланганчы, шырпы кабызырга кирәклекне онытабыз

> 3

ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕ

Әгәр сине аңламыйлар яки дөрес аңламыйлар икән, моңа үртәлергә ярамый

> 4



35 СЕЗОН

Үзгәртергә тырышсалар да, Салават үзгәрми

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 114 (29081) | Чәршәмбе | 9 август | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ХЫЯЛ КҮПЕРЕ

Төзелеш

Төзүчеләрнең биелгы һөнәри бәйрәме аеруча истә калачак. Ник дигәндә, кичә Татарстанда М12 трассасы юлында Идел аша төзелә торган күперне тоташтырдылар. Шул рәвешле республиканың Югары Ослан һәм Лаеш районы ярларын 45 мең тонналык металл тоташтырды. Күпернең озынлыгы – 3362 м.

Тантаналы чарада катнашкан Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов сүзләре белән әйтсәк, хыял буларак чынга ашкан күпер бу.

– Хыяллар чынга аша. Кайчан гына Идел аша күпер турында хыяллана идек. Менә бүген инде бу күперне тоташтырабыз. Форсаттан файдаланып, Россия Президенты Владимир Путинга, Хөкүмәтебезгә, Марат Хөснуллинга, барлык юл төзүчеләргә, күпер төзүчеләргә, «Автодор» оешмасына рәхмәт сүзләре җиткерәсем килә. Төзүчеләрне якынлашып килүче һөнәри бәйрәмнәре белән котлыйм, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Идел аша салынган бу күпер М12 трассасындагы иң озын ясалма корылма санала. Билгеле булганча, Мәскәү, Түбән Новгород, Казанны тоташтырачак трасса «Магистраль инфраструктураны яңарту һәм киңәйтү» илкүләм проекты кысасында төзелә. М12 трассасы икътисадка уңай йогынты ясар, 17 эре төбәкне тоташтырыр дип көтелә. Моннан тыш яңа трасса пәйда булгач, Мәскәү – Казан юлындагы юл фаҗигаләре дә 3,5 тапкыр кимер дип фаразлана.

Россия Премьер-министры урынбасары Марат Хөснуллин кичәге вакыйганы төзүчеләрнең һөнәри бәйрәме алдыннан илебезгә ясалган зур бүләк дип атады. Ул тантаналы чарада видеоэлемтә аша катнашты.

– 2020 елның 10 июлендә Хөкүмәт тарафыннан Россиядәге иң зур юл төзелешенә тотыну турында карар кабул ителде. Шул рәвешле гомуми озынлыгы 810 чакрым булган М12 трассасы төзелешенә керештек. Узган ел трассаның Мәскәү, Владимир өлкәләренә туры килгән 107 чакрымлык өлеше сафка басты. Сентябрьдә инде Арзамаска кадәрге юлны ачарга җыенабыз. Бу инде эшнең яртысы тәмамланган дигән сүз булачак. Ел азагына кадәр Казанга илтүче юл да тулысынча ачылыр дип өметләнәбез. 2024 елда исә – Санкт-Петербург юнәлешендәге, 2025 елда Төмәндәге юл ачылыр дип планлаштырабыз, – дип сөйләде ул, якташларын сәламләп.

Марат Хөснуллин сүзләренә караганда, яңа күпер Иделнең уң як ярында инфраструктура үсешенә зур этәргеч бирәчәк. Моннан тыш ул гамәлдәге юлларны да бераз «бушатыр» дип көтелә.

Россиянең транспорт министры Виталий Савельев яшерми: күпер төзүче тәҗрибәле, оста белгечләр булмаса, мондый зур эшләр хыялда гына калган булыр иде. Министр сүзләренә караганда, бүген ил күләмендә шундый зур объектлар төзелә.

– Ерак Көнчыгыш, Благовещенскида, Тверь өлкәсендәге күперләр шулар рәтендә. Чаллыда да Кама аша күпер төзелә, – диде министр.

Идел аша сузылган яңа күпердән ел азагында файдалана башлыйбыз. М12 трассасының сигезенче этабы төзелешен җитәкләүче Рәшит Хәҗипов шулай дип ышандыра.

– Күпернең терәүләрен төзү, металл корылмаларына бәйле эшләр планлаштырылган вакыттан бер айга иртәрәк тәмамланды. Быел октябрь азагына кадәр асфальт түшәп бетерергә җыенабыз, – ди белгеч.

tatarstan.ru

Күпер корылмаларын рәткә китерү буенча эшләр бара. Эшләр 44 күпердә башкарыла, аларның гомуми озынлыгы 2 мең метрдан артык, шуларның 26сы милли проект кысасында. 6 объект файдалануга тапшырылган, 38ендә эшләр дәвам итә.

ИДЕЛ АША СУЗЫЛГАН КҮПЕР ТӨЗЕЛЕШЕНДӘ

- 4 меңнән артык кеше катнашкан, 1 мең берәмлек техника җәлеп ителгән;
- аның терәүләрен, металл корылмаларын җыю өчен 20,5 ай вакыт таләп ителгән;
- күпер быелның декабрендә тулысынча сафка басачак.

Өч тапкыр арткан

Чамадан тыш эсселек һәм озакка сузылган корылык. Быел җәен шул сәбәпле урманнар тирәсендә янгыннар саны узган елның шушы ук чорындагыга караганда 3 тапкыр арткан. Урман хуҗалыгы министры Равил Кузюров әйтүенчә, ел башыннан чиктәш урыннарда 830 янгын очрагы, 985 термик нокта (әйтик, чүп, басуда камыл яну шуңа керә) теркәлгән.

Министр искә төшереп узганча, май азагында Әлмәт районы урманында 0,5 гектар мәйданда янгын булган. Ут, каты калдыклар полигонында чыгып, агачларга күчкән. Әле ярый янгынны тиз генә сүндерүгә ирешелгән.

Шунысы игътибарга лаек: узган елда урман янгыннары гомумән булмаган. Ә менә 2021 елда 19 янгын очрагы теркәлгән (барлыгы 210 гектар мәйданда).

Яңа кармак

Мошенниклар интернетка вируслы документ өлгеләрен урнаштыра башлаган. Үзәк банкның телеграм-каналында хәбәр ителгәнчә, документлар белән эшләүчеләр – хисапчы, сәркатип, финанс, салым белгечләре яңа кармакка ешрак эләгә.

Шундый документ өлгесен үзеңдә урнаштыруга, компьютерда «удаленный доступ» программасы эшли башлый. Мошенниклар шуның ярдәмендә төрле алдауларга һәм акча урлауга барырга мөмкин. Үзәк банк белгечләре, мондый хәлгә юлыкмас өчен, антивирусны даими яңартырга, компьютерда программаларны автомат урнаштыруны тыюны көйләргә киңәш итә.

Безне сайлыйлар

Казан университетларына чит илләрдән 25130 егет-кыз гариза тапшырган. 65ләп илдән килгән абитуриент КФУ, КНИТУ-КАИ, Казан дәүләт энергетика университетын сайлаган.

Шәһәр мэры матбугат хезмәте хәбәренә караганда, КНИТУ-КАИга 13,5 меңгә якын гариза керсә, шуның 1,4 меңе – 20 илдән килгән яшьләрнеке. Алар арасында Беларусь, Казахстан, Кытай, Мисыр, Согуд Гарәбстаны, Колумбия, Нигерия, Төркия кебек илләрдән килүчеләр күп. Вузда «авиатөзелеш», «радиоэлектроника», «мәгълүмат технологияләре» һәм «икътисад» юнәлешләре буенча зур конкурс барлыкка килгән.

Энергетика университетына исә 13 меңнән артык гариза тапшырылган. Шуның 230ы – чит ил абитуриентларыннан. Аларны бигрәк тә «атом-төш станцияләре», электр энергетикасы» кебек белгечлекләр кызыксындыра.

КФУның кабул итү комиссиясенә исә 243 мең гариза кергән. 23,54 меңе – 65 илдән килгән яшьләрдән. Арада Алжир, Кытай, Куба, Греция, Мексика, Төркиядән килүчеләр байтак. Биредә «лингвистика», «бизнес-информатика», «халыкара мөнәсәбәтләр» белгечлекләре буенча белем алуга зур ихтыяҗ күзәтелә.

Яңалык

Сакла, онытылмасын!

РОССИЯ ХАЛЫКЛАРЫНЫҢ БИЮ, ЙОЛА, ӘКИЯТЛӘРЕН ЗАКОН САКЛАЯЧАК

Әкият, йола, кәсеп – барысын да сакларга. Россиядә матди булмаган этномәдәни байлык объектларының федераль реестры булдырылачак. Тиешле карарны Премьер-министр Михаил Мишустин имзалады.

Мәгълүм булганча, Россиядә 190нан артык милләт һәм этник төркем вәкилләре яши. Һәрберсенең үзенә генә хас традицияләре, һөнәрләре, җыр-биюләре, риваятьләре бар. Былтыр ук боларның барысын да «матди булмаган этномәдәни байлык» төшенчәсенә берләштергәннәр иде.

Реестрда традицион мәдәниятне саклаучылар, матди булмаган байлык саналган объектның килеп чыгышы, территориясе турында мәгълүматлар урнаштырылачак.

Реестрга эләгүнең шартлары да бар. Теге яки бу матди булмаган этномәдәни байлык объектының мәҗбүри таләпләргә туры килүе мөһим. Болар:

- *этник үзенчәлекне чагылдыруы, тарихи, мәдәни, фәнни кыйммәткә ия булуы;*
- *объектның яше – 40 ел яисә 40 елдан артыграк;*
- *объектның югалу куркынычы булу.*

Әлеге реестр матди булмаган байлык белән эш итүчеләргә нигез булып торыр дип өметләнәләр. Әйтик, Дәүләт Думасының икътисадый сәясәт комитеты рәисе урынбасары Станислав Наумов фикеренчә, күпмилләтле илдә моңа аеруча игътибар бирелергә тиеш. Депутат әйтүенчә, киләчәктә әлеге реестрга аерым җирлекләрнең үзенчәлекле мирасын да кертеп булыр иде: «Мисал өчен, минем туган җирем – Чиләбе өлкәсенең Нагайбак районында аларга гына хас җырлар, бизәкләр, орнаментлар бар. Аларны да реестрга кертеп булыр иде», – ди ул.

Гомумән, бу реестр матди булмаган байлыкны өйрәнү, эзләнүгә бер этәргеч тә булмагае. Әйтик, илнең кайбер төбәкләрендә кыз сорау һәм туй йолалары үзенчәлекле үтә (Осетия). Псков өлкәсендә кыр эшләренә бәйле йолалар сакланып калган. Смоленщинада исә Иван Купала бәйрәме алдыннан башкарыла торган йолаларны әле дә үтиләр.

Сүзгә-сүз

Борис ЧЕРНЫШОВ, Дәүләт Думасы Рәисе урынбасары:

Хатын-кызга ана капиталын белем алу өчен тотарга мөмкинлек бирергә кирәк. Ата-ананың белем дәрәҗәсе никадәр югары булса, кереме дә шулкадәр югарырак, димәк, баланы тәэмин итү өчен, мөмкинлекләр дә зуррак булачак. Ана капиталын белем алуга тоту – отышлы һәм ышанычлы инвестиция, ул киләчәктә күп тапкыр үзен аклаячак.

(«Парламентская газета»дан)

БАЛАЛАРГА КЕСӘ АКЧАСЫ БИРӘСЕЗМЕ?

«Росгосстрах Жизнь» компаниясе һәм «Открытие» банкы Россиядә яшәүче ата-аналарга шул сорауны биргән. Белгечләр ачыклаганча, ата-аналарның 69 проценты балаларының вак-төяк чыгымнарына кесә акчасы бирә.



КҮПМЕ БИРӘЛӘР? (1 айга)

- **31%** >> 1 мең сумга кадәр
- **27%** >> 1–3 мең сум
- **28%** >> 3–5 мең сум
- **24%** >> 5 мең сумнан күбрәк

Су шуклыкны кичерми

Татарстанда җәй башыннан бирле 47 кеше суга батып үлгән. Шуның өчесе – балалар. Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсе матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, фаҗигаләрнең төп сәбәбе тиешсез җирләрдә су коенуга һәм ваемсызлыкка бәйле. Бары тик махсус җиһазландырылган урыннарда гына су керергә кирәк. Шунысын да белеп торасы: кояш күзендә озак булганнан соң суга ыргылып кереп китәргә ярамый. Су температурасы һаваныкыннан кимрәк, шуңа күрә тәнне көзән җыерырга мөмкин.

Тулаем Россиягә килсәк, июль аенда гына да суда 900дән артыграк кешенең гомере өзелгән. Бу саннан 3 тапкыр кимрәк кешене коткарып калганнар. Балаларның үзләрен генә су тирәсенә җибәрүчеләр бар. Коену сезоны башланганнан бирле МЧС хезмәткәрләренә 6,7 мең малай-кызны яр буеннан озатып, әти-әниләренә тапшырырга туры килгән. МЧС башлыгы Александр Куренков фикеренчә, балаларның фаҗигагә юлыгуының иң киң таралган сәбәбе – аларга күз-колак булмау. Су шуклыкны, битарафлыкны кичерми.

mchs.gov.ru

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ӘЛЛӘ СӘҮДӘ ҖАНЛАНА, ӘЛЛӘ...

Дөньякүләм статистика 2022 ел йомгакларын исәпләвен дәвам итә. Беренче карашка саннар ярыйсы гына кебек. Планета масштабында сәүдә үткән ел 11 процентка үскән. Ике урынлы үсеш темпы кризис юклыгын раслый шикелле. Әмма сәүдәнең акчалата күләме генә шулай тышаудан ычкынган төсле алга ыргыла. Энергия чыганакларына, азык-төлеккә, ашламаларга күтәрелгән бәяләр, икенче төрле әйтсәк, инфляция үсешне шулай матур бизәкләп күрсәтә. Товар алмашуның физик күләмнәре ыргылыш турында сөйләми. Физик күләмнәрдә сәүдә бары тик 2,7 процентка гына үскән, ди Бөтендөнья сәүдә оешмасы мәгълүматлары. Сүз дә юк, монысы да – үсеш инде, әмма ел ахырында товар әйләнеше саннары тискәре якка киткән шул. Соңгы кварталда, өченче квартал белән чагыштырганда, халыкара товар алмашу 2,1 процентка кимегән. 2023 елның беренче кварталы күрсәткече дә минуста. Кимү – 0,3 процент.

Дөнья сәүдәсенең структурасы да мактанырлык түгел. Сәнәгать товарлары сату кими, чимал һәм ягулык сәүдәсе арта. 2021 елда сәүдәдә сәнәгать товарлары өлеше 69 процент булса, үткән ел – 63 процент кына.

Зур державалар үзара сәүдәне үзгәртеп корырга тырыша. Бигрәк тә Кытайдан товар алуны кимету тенденциясе көчәя. АКШның аннан импорты быел биш айда 24 процентка кимегән. «Дөнья фабрикасы» исемен йөрткән илнең хәлен шуннан күз алдына китерегез. Financial Times кытай икътисадчыларына икътисадтагы тискәре хәлләрне телгә алуның тыелуын яза. Дефляция турында, илдән капитал качу турында бөтенләй сөйләргә ярамый.

Төзелеш гиганты «Evergrande»ны коткару чиннарга кыйммәткә төшә. Исегезгә төшерәбез: бу компаниянең дефолт һәм банкротлык алдында торуын без байтактан язабыз. Бер аның гына түгел, башка төзелеш компанияләренең дә хәле мөшкел. Алар дефолт игълан итсә, кытай икътисады җимерелеп кенә төшәчәк иде. Моны булдырмас өчен, хөкүмәт «Evergrande»га финанс ярдәме оештырды: бурычларын түләргә акча бирде. Кытай икътисадында бернинди дә кризис юк дигән тәэсир калсын өчен, күп акча тотылды. Төзүчеләр Үзәк банк акчасы хисабына гына яши башладылар. Ярдәм акчалары төзелешне арттырмады, бурычларны гына үстерде. «Evergrande»ның 2022 елда 278 миллиард долларга тиң булган әҗәте 2023 ел башына 348 миллиардка кадәр үсте. Кечерәк бурычны түли алмаган компания зуррагын түли алмаячак, билгеле. Эмиссия – акча басу – зур инфляция вәгъдә итә. Кытай ике куркыныч яр – инфляция белән ипотека кризисы арасында бәргәләнә. Бу протестлар башлану куркынычын тудыра. Быелның маенда төзелеш компанияләре тарафыннан алданган халык Янчжоуда демонстрациягә чыкты инде. Компартия халыкны никадәр генә кытыршы бияләйләр белән тотмасын, массакүләм протестны бастырып булмаячагын аңлый. Ковид чикләүләренә каршы протестлар моны раслады инде. «Инфляция кузгатачак халык ачуын кая юнәлтергә?» дигән сорау Си командасын бик борчый, диләр.

Россиядә

СУМНЫ СОҢГЫ ЮЛГА ОЗАТУ

Соңгы көннәрдә сум – доллар бил алышуы игътибар үзәгендә. Дүшәмбе сәүдәсенең долларны 97 сумга кадәр күтәрүе аптыраш тудыра. Кайбер икътисадчылар, Россия җитәкчелеге моннан ел ярым элек кабул иткән карарлар шулай «ата», диләр. Валюта базарында «август ләгънәте» диючеләр бар. Соңгы утыз елдан артык вакыт эчендә август ае зур түнтәрелешләр һәм бәхетсезлекләр белән хәтергә кереп калды шул. 1998 елгы дефолтта сумның мәтәлчеге, долларның берничә тапкыр кыйммәтләнеп, безне йомшак җәеп катыга утыртуы аеруча йөрәккә уелды. «Акчасызлык-кыйммәтчелек җитәкләшеп йөргән шул вакытлар яңадан әйләнеп кайтамы?» дигән сорау күңелләрне борчый башлады.

Сумның тез буыннары калтырау һәм үзенең җеназасын көткән кебек кылануы нефтькә бәяләр үсү фонында бару да аптырата. Россия нефте, Көнбатыш куйган түшәмне җимереп, югарыга китте, дигән хәбәрләр ишетелеп тора югыйсә. Андый чакта сум гел җанлана, ныгый иде. Аек акыл бу юлы да шулай булырга тиеш дип ышана.

Сумның очсызлануы объектив һәм субъектив факторларның үзара үрелүе сәбәпле бара. Әйе, чимал экспорты ярыйсы гына саннар күрсәтә. Хәтта углеводород табышы үсә башлады, бюджетка ярыйсы гына акча коячак, диләр. Әмма сәүдә долларларда бармый шул. Чимал алучылар безгә конвертацияләнми торган валюталар белән түли. Ел ярым элек кабул ителгән карар дигәндә, икътисадчылар шуны күз алдында тота. Импортерларга исә юань да түгел, рупия белән дирһәмнәр дә түгел, доллар яисә евролар кирәк. Җитмәсә, импорт үсә башлады. Чит илгә барыйк дисәк, үзебез дә бит банк тәрәзәсеннән доллар сорыйбыз.

Россия хакимиятләренә сумның йомшак булуы файдалы дигән субъектив факторны күпчелек аналитиклар телгә ала. Долларның бер сумга кыйммәтләнүе бюджетка 120 миллиард сум акча бирә, диләр. Курс менә шушы хәлдә торса, калган биш айда казнага триллион сумга якын акча керәчәк икән. Казна тишеге исә бик зур, шуңа күрә доллар түшәменең йөз сумнан да ашып китүенә гаҗәпләнмәскә кушалар. «Доллар кыйммәтләнгәч, казнага акчаны кем бирә?» дигән сорауның җавабы гади: халык кесәсендәге акча кыйммәтләнгән товар сатып алу рәвешендә бюджетка таба шуа. Турыдан-туры доллар сатып алып та казнаны тутыруга өлеш кертә алабыз. Финанс министры диванда тик ятып та акча эшли ала мондый вазгыятьтә.

Халыкара киеренкелек факторы бар. «Ашлык килешүе»ннән чыкканнан соң, төрекләр Россия чималын алуны кискен киметкән, мәсәлән. Әрдоган хәйләкәр ул, кайсы нокталарга басасын яхшы белә. Чимал товарларын алуны – 20 процентка, чимал булмаган Россия товарларын импортлауны 54 процентка кыскан. Төрек лидеры якындагы көннәрдә Путин белән Зеленскийны сөйләшүләр өстәле янына өстерәп китерергә ниятли. Ул ният тормышка ашсын дип кенә телик инде. Югыйсә рәсми Россия матбугаты: «Сумның тотрыклану факторлары калмады», – дип яза башлады. Тормозсыз валюта кемгә кирәк?!

Хәерле юл!

НИГЕЗЕНДӘ – МИЛЛИАРДЛАР

86,8 млрд сум! 2023 елда юл төзү һәм төзекләндерү эшләренә шулкадәр акча бүлеп биреләчәк. Быел былтыргыга караганда 19,4 млрд сумга күбрәк акча тотылачак. Аңлашыла да: соңгы арада Татарстанда юл эшләренең тынганы да юк. Яңасын түшәп бетерәсе, начар хәлдәгесен ямыйсы, ачылганын тәртиптә тотасы бар.

tatarstan.ru

Тотып карамыйча ышанмыйм дигәндәй, акчаның нинди максатларга тотыласына күз салыйк.

__28,5__ млрд сум – «Алексеевск – Әлмәт» юлы төзелеше
__15,9__ млрд сум – юлларны капиталь төзекләндерү
__14,7__ млрд сум – «Куркынычсыз имин юллар» илкүләм проекты
__13,7__ млрд сум – юл төзү һәм төзекләндерү
__7,7__ млрд сум – юлларны тәртиптә тоту
__2,6__ млрд сум– авыл юллары, бакчачылык ширкәтләренә илтүче юллар
__1,3__ млрд сум – муниципаль юл фонды
__1әр__ млрд сум – төрле ремонт эшләре

Юлларның нинди булуы автомобиль катнашындагы фаҗигаләр санына да бәйле. Татарстан транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары Артем Чукин әйтүенчә, быел республика территориясе юлларында 161 куркыныч саналган участокны юк иткәннәр. Быел төбәк әһәмиятендәге юлларга махсус билгеләр ясый башлаганнар, алар «тимер ат» ияләренә юлның бу өлешендә каршыга чыгып узып китү тыелганын искәртә.

2023 елның беренче яртыеллыгы нәтиҗәләре буенча юл-транспорт һәлакәтләре арткан юлларны төзекләндерүгә тотынмакчылар.

– Аеруча күп мөрәҗәгатьләр Тукай, Сарман районнарыннан килде. Авария саны арткан төбәк әһәмиятендәге юллар билгеләнде. Өстәмә акча бүлеп бирү кысасында Чаллы – Сарман, Чаллы – Зәй – Әлмәт, Казан – Шәмәрдән, Чистай – Аксубай – Нурлат юлларындагы участокларга ремонт каралган, – диде Артем Чукин.

Министр урынбасары әйтүенчә, юл-транспорт һәлакәтләре күп булган участоклар саны кими. Аварияләрдә үлүчеләр саны белән дә шул ук хәл. Юл хәрәкәте иминлеген яхшырту программалары буенча, быел Татарстан юлларында үлем-китем күрсәткече 100 мең кешегә 7,55тән артмаска тиеш. Артем Чукин әйтүенчә, быелның алты аенда әлеге күрсәткеч 3,21не тәшкил итә.

Казан халкын борчыган сорауга да җавап бар. Ул да булса «Миллениум» күперендәге ремонт барышы. Эшләр кайчан төгәлләнер?

– 30 августка яки сентябрь башына, – диде ул. Монысы – әле юлчылар башкарасы эшнең беренче этабы гына. Кем әйтмешли, яхшы юлдан йөрисе килсә, «бөке»ләргә сабыр итми чара юк.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

АЛДЫНГЫЛАР ҖӘЕ

Лагерьда, форумда, урамда, ишегалдында, паркта... Кыскасы, балалар һәм үсмерләр кайда – «Алдынгылар хәрәкәте» шунда. Күптән түгел генә оешса да, җәй дәвамында 21 меңләп баланы колачларга өлгергән ул. Әлеге хәрәкәтнең җәйге чаралары турында Хөкүмәт йортында узган брифингта сөйләделәр.

vk.com

Әле бу елның кыш айларында эш юнәлешләрен генә тәгаенләгән «Алдынгылар хәрәкәте», җәйне нәтиҗәле уздыру максатыннан, автобуска утырып, районнар буйлап та йөргән, экстрим-паркларда, ишегалларында чаралар да уздырган. Татарстан Рәисе ярдәмчесе, «Алдынгылар хәрәкәте»нең республикадагы бүлеге җитәкчесе Тимур Сөләйманов сүзләре белән әйтсәк, балаларның җәйге ялын төрле яклап колачларга тырышканнар.

– Әлеге хәрәкәт күптән түгел генә барлыкка килсә дә, бүгенгә кадәр шактый эшләр башкарылды. Һәр районда балалардан команда тупланды. Без Татарстан мәктәпләренең директорлары, директор урынбасарлары белән очраштык. Һәм җәйге сезон башланыр алдыннан, бу хәрәкәт турында азмы-күпме белүчеләр, аның ни өчен кирәк икәнен аңлаучылар тупланып өлгерде. «Алдынгылар хәрәкәте» турында сөйләшкәндә, саннар теленә күчәсем килми. Безнең өчен сыйфат күпкә мөһимрәк. Әмма бу хәрәкәттә инде җәй башыннан ук актив катнашучы балалар һәм үсмерләр саны – өч-дүрт мең тирәсе, ә укып чыккан остазлар саны ике меңләп булды дип әйтә алабыз. Быел җәй без мөмкин кадәр күбрәк кешене «Алдынгылар хәрәкәте» белән таныштыру максатын куеп эшләдек. Иң беренче чиратта игътибарны җәйге профильле сменаларга юнәлттек, – дип сөйләде ул.

Татарстан яшьләр эшләре министрының беренче урынбасары Софья Мостафина кайбер сменаларга аерым тукталды.

Фикер

Тимур СӨЛӘЙМАНОВ,
«Алдынгылар хәрәкәте»нең Татарстан бүлеге җитәкчесе:
– Балаларның җәйге ялы көн һәм йокы режимы, саф һавадагы уеннар гына түгел бит әле ул. Җәйге ялның эчтәлеге дә мөһим. Ул эчтәлеккә нинди мәгънә, нинди кыйммәтләр салынган? Киләсе җәйгә планнарыбыз зурдан. Нәкъ менә эчтәлеккә басым ясыйсы иде.

«Алдынгылар хәрәкәте»нең җәйге чаралары – саннарда:
- ➤ **21** меңләп баланы колачлаган;
- ➤ **600**ләп бала катнашында **5** профильле смена һәм **2** меңләп бала катнашында **3** форум узган;
- ➤ республиканың **7** районында (Чаллы, Лениногорск, Зәй, Бөгелмә, Әлмәт, Яшел Үзән, Түбән Кама) ишегалды лагерьлары эшләгән, аларда **1600** бала катнашкан;
- ➤ «Алдынгылар заманы» автобус туры Татарстанның **14** районындагы **20** лагерьда ял итүче **3760** баланы колачлаган;
- ➤ июньдә мәктәпләр һәм көллиятләрдә тәрбия эше буенча директор урынбасары булып эшләүче **700** хезмәткәр өчен укулар узган. Августта әлеге белем бирү программасын тагын **774** педагог үтәчәк.

– «Алдынгылар хәрәкәте» уздырган сменаларда балалар белән бик зур тәрбияви эш алып барыла. Әйтик, «Игелек командасы» сменасын гына алыйк. Ул 21 августка кадәр дәвам итәчәк. Сменаның төп максаты – катнашучыларны волонтерлар һәм иреклеләр эшчәнлеге белән таныштыру. Миңа калса, яхшылык, изгелек эшләргә омтылып яшәүчеләр турында балалар кечкенәдән үк белергә һәм аларның эшчәнлегенә шундый зур хәрәкәтләрдә аерым игътибар бирелергә тиеш, – диде ул.

Билгеле, бер бездә генә түгел, «Алдынгылар хәрәкәте» бөтен Россия буйлап атлый. Әмма күп нәрсәдә Татарстан беренче булачак. Әйтик, 1 сентябрьдән «Алдынгылар хәрәкәте»нең Татарстандагы бүлеге, Россия күләмендә беренче булып, үз эшчәнлеген балалар бакчаларында да башлаячак.

– Моннан тыш, хәрәкәтнең Биләрдә «Сәләт» белән бергә уздыра торган форумында 11 августта «Алдынгылар хәрәкәте»нә кабул итү, багышлау чарасы узачак. Шулай ук Россиядә беренче тапкыр. Махсус ант сүзләре һәм атрибутикасын да әзерләдек. Беренче булып бу антны хәрәкәтебезнең җитәкчесе Григорий Гуров әйтер дип өметләнәм, – дип сөйләде Тимур Сөләйманов.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

КОМБАЙНЧЫ РӘМЗИЯ:

«ЯРАТУ ЭШНЕ ҖИҢЕЛӘЙТӘ»

Җир кешесе

Яратып эшләсәң, авыр эш тә җиңеләя. Арча районының бердәнбер хатын-кыз комбайн ярдәмчесе Рәмзия Хәбибуллинаның чын күңелдән әйткән сүзләре бу. Әлеге тырыш һәм үҗәт хезмәт кешесе белән эш һәм аш кадере турында сөйләштек.

Рәмзия апа тумышы белән Арча районының Шекә авылыннан. Техникага, ир-ат эшенә хирыслык бала вакытыннан ук килә торгандыр.

– Әтиебез сугышта бер кулын имгәтеп кайткан. Өч абыем булса да, төрлесе төрле якка сибелгәч, мин, төпчекләре, әти-әнинең төп ярдәмчеләре булып калдым. Үткенлегем, үҗәтлегем исә әнидән күчкәндер. Кыз чагымда ук: «Әйдә, пычкыны тотып тор, балтаны тотып тор, кадак бирел тор», – дия-дия, үз яныннан җибәрмәде ул мине. Лапас түбәсенә кадәр япкан идек икәү бергә. Шуңа күрә эшне кечкенәдән үк яратып үскәнмендер.

Мәктәпне тәмамлагач, бухгалтер һөнәрен үзләштерә тоташ. Аннан Шушмабаш сәүдә берләшмәсенә эшкә урнаша. Шул елларда озак очрашып йөргән Рәдифе белән дә кавышып куялар. Тырышлыклары белән дан казанган нәселле йортка – Мәмсә авылына килен булып төшә ул. Каенатасы да гомер буе комбайнда эшләп, алдынгылыкны бирмәгән кеше була. Ире Рәдиф тә сынатмый, нәкъ менә Рәмзиясе хыялындагы ир булып чыга. Тырыш, сабыр, күркәм гаиләнең бер-бер артлы кызлары һәм уллары дөньяга килә. Кызганыч, улларының гомере кыска булып чыга: биш ел элек мәрхүм була ул.

– Улым Рәмис бала-чага вакытыннан ук әтисе белән «Дон» комбайнына утырып йөрде. Зуррак сыйныфларда аның ярдәмчесе булып эшли башлады. Улым кечерәк чакта үзем дә аларга ияреп йөрдем. Шулай итеп, биш ел иремнең ярдәмчесе булып эшләдем, – диде Рәмзия апа, кыр корабын иярли башлаган вакытларын искә алып.

Шуннан соң озак еллар «Ташкичү» хуҗалыгы амбарында, башка эшләрдә эшли әле ул. Ә комбайн штурвалы артына кабат әйләнеп кайтуы 2018 елда була. Ире янына ярдәмче итеп дәшеп алалар аны. Рәдиф абый ял иткән арада, штурвал артына да утырырга, бункерны да бушатырга туры килә. Кабинаны, иләкләрне, фильтрны карап-чистартып тору да – аның җаваплылыгында. Дөрес, күпчелек эшләр 42 ел стажлы, тәҗрибәле комбайнчы Рәдиф абыйның ярдәме белән башкарыла.

«Хатын-кызның йортта да эше кырыкмаса-кырык якка таралып ята, аларына ничек өлгерәсез?» – дип тә сорамый кала алмадык ут кебек чая комбайнчыдан.

– Малларны да карарга, кош-кортын да үстерергә өлгерәм. Ашарга исә төнлә әзерлим. Мине юкка гына «Шекә пәрие» димиләрдер инде. Минем бит өч киленем – ярдәмчеләрем бар, – дип, ихластан көлеп җибәрде ул, кер, савыт-саба юу машиналарын һәм тузан суырткычны күз алдында тотып.

Рәмзия апаның сабырлыгы, үҗәтлеге, булдырам дип тырышуы комбайн штурвалы артында чарлана. Эссе җәйге кояш астында, тузан йотып, бер караңгыдан икенчесенә кадәр штурвал киеренкелеген тоеп, икмәк өчен барган көрәшне җиңеп чыгар идеме икән ул нәфис куллар?

– Кызым, эшнең бөтенесе дә авыр аның. Ләкин аны яратып эшләсәң, җиңеләя ул. Барысы да үзең ничек кабул итүдән тора, – ди ул. – Мин 27 ел амбарда эшләдем. Без, ике хатын-кыз, озак еллар шушы кырлардан кайткан ашлыкны кыш буе орлык өчен әзерләдек. Соңгы елларда Рәдиф абыең белән ашлыкны үзебез агулыйбыз, үзебез төйибез, «бисмилла»ны әйтеп, басуга чыгарып җибәрәбез, шуны кабат үзебез җыеп та алабыз. Ашлык белән бәйләнештә булгангамы, эшемне яратып башкарам. Авырлыгын да сизмим. Ә бит килен булып төшкәндә арпа белән бодайны да аермый идем мин! Хуҗаларга да рәхмәт. Игенчеләргә игътибар бик зур бездә.

Шушы еллар эчендә шаяртып та, төрттереп тә: «Тимер-томыр арасында синә ни калган?» – диючесе дә, «Көн буе ирегез белән бергә булу туйдырмыймы?» – диючеләре дә булгалаган. Тик алар гына күңелен төшермәгән Рәмзия апаның.

– Кырын караш ташлаучылар бардыр инде, бәлки, ләкин аларның берсе дә минем эчемдәгесен белми. Рәдиф абыегыз яхшы булганга, аңа ярдәмем тияр дип тотынган эшем бу, – диде ул. – Әйе, комбайн эшен бик яратам! Минем халәтне үзе штурвал артына утырып карамаган кеше аңламый. Өстән табигатьне күзәтү генә дә ни тора?! Сезнең кояш баеган вакытта сап-сары ашлык басуын күргәнегез бармы? Яки агачларның талгын җилдә тирбәлеп утыруларын күзәткәнегез бармы? Яисә комбайн артыннан теземнәрнең җепкә тезеп салган кебек тип-тигез булып ятып калуларын? Мин менә шуларга сокланып карап туя алмыйм. Үлчәүгә эшнең авырлыкларын һәм рәхәтлекләрен салсаң, икенчеләре барыбер өстен чыгар.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ТАТАРСТАНДА УРЫП-ҖЫЮ БАРЫШЫ

Районнар	Суктырылган мәйданнар (гектар)	Җыелган ашлык (мең тонна)	Уңдырышлылык
Әгерҗе	8446	16,8	19,9
Азнакай	11474	19,1	16,6
Әлки	24053	70,4	29,3
Балтач	12353	40,6	32,9
Буа	25095	79,0	31,5
Кайбыч	12998	49,6	38,2
Кукмара	10393	34,4	33,1
Яңа Чишмә	19887	52,3	26,3
Нурлат	21612	65,7	30,4
Питрәч	10124	30,8	30,5
Сарман	18959	41,2	21,7
Чирмешән	14243	25,3	17,8
Ютазы	7413	12,4	16,8

Татарстанның Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәгълүматлары буенча, 603 мең 716 гектар мәйданнан 1 млн 679,9 мең тонна ашлык җыеп алынган. Бүгенгә барлык мәйданнарның 40 процентында эшләр тәмамланган. Республика буенча уртача уңдырышлылык – гектарыннан 27,8 центнер.

НАДИР БАҺАВИЕВ: «СУДА АТЛЫЙ ТОРГАН МАШИНА ФАНТАСТИКА ТҮГЕЛ»

Җәһәт әңгәмә

Тиздән, елның нинди фасылы булуына карамастан, Идел буйлап моңарчы күзгә күренмәгән транспорт йөри башласа, гаҗәпләнмәгез. Америка Кушма Штатларының Эмбри-Риддл Аэронавтика университетында аэрокосмик инженер белеме алып кайткан милләттәшебез Надир БАҺАВИЕВ эше булыр бу. Ул хәзер Казанда яши. Татар конструкторлар бюросы төзү турында хыяллана. Әлегә су һәм боз өстендә бер үк дәрәҗәдә яхшы йөри алучы Суатлар (ягъни су атлары була инде) дип аталган транспорт моделен камилләштерү белән шөгыльләнә.

:: Надир, белүемчә, моннан ике ел элек син Америкадан шактый зур планнар белән кайткан идең. Уй-хыялларың тормышка ашамы?

– Укуны тәмамлагач, мин Америкада төрле аэрокосмик компанияләрдә эшләдем. Соңрак үз компаниямне булдырдым һәм 3D принтерда ракета этәргечләрен бастырып, тәҗрибәләр үткәрдем. Туган җиремә кайтуым сагынуга бәйле дисәм, бик примитив булыр. Анысы да бар. Туып-үскән Казанымның һәр почмагы кадерле миңа. Әмма хыялым башка. Соңгы араларда Казан Россиядә генә түгел, дөнья күләмендә бик җитди инженерлык үзәге булып танылды. Татар кешесе буларак, мин моны читтән генә күзәтеп тора алмадым, әлбәттә. Ничек тә җаен табып, шул дулкынга керәп китәргә иде исәбем. Әгәр дә зур принтер һәм орбиталь ракета турындагы хыялларны тормышка ашыра алсак, бу Татарстанга дөнья күләменә чыгарга мөмкинлек бирер иде.

:: Татар конструкторлар бюросында ниләр белән шөгыльләнергә ниятлисез?

– Бүген металл белән бастыра торган 3D принтерлар – заманча икътисад өчен бик мөһим машиналар. Мөмкинлек табып, без аларны, һичшиксез, Татарстанда төзергә тиеш. Әйтергә кирәк, мондый принтерлар ракета төзелешендә генә түгел, автомобиль, су машиналары, вертолет һәм самолет төзелешендә дә бик мөһим роль уйнар дип көтелә.

Ниһаять, мондый принтерлар нефть чыгару насослары өчен моңа кадәр чит илдән кертелгән детальләрне үзебездә булдыру өчен дә кирәк. Кыскасы, аның мөһимлеген әйтеп бетерә торган гына түгел. Ахыр чиктә, Татар конструкторлар бюросы илебезгә, халкыбызга күп кенә файдалы җиһазлар да ясый ала. Мәсәлән, авыл тормышында кирәкле кар көри, печән җыя һәм башка эшләрне башкара торган роботлар. Шулай ук авыл һәм шәһәр арасындагы тиз йөрешле авиаэлектр транспорты, кыр эшләре роботларын да ясарга була.

Татарстан күз ияргәслек тизлектә логистик үзәккә әверелә бара. Тимер юл, су юлы һәм гади юл транспортларын тоташтыручы роботлаштырылган портлар барлыкка китерүдә дә Татар конструкторлар бюросы зур роль уйнар иде. Тора-бара гомерне озынайту һәм биопринтерларда яңа әгъзалар бастыру, оптик санаклар ясау эшләренә дә тотынырга була.

:: Эшне нәрсәдән башларга җыенасыз?

– Эш башланды инде. Алда әйтеп үтелгән Суатлар моделенә Кабан күлендә сынау үткәрдек. Хәзер өч урынлы транспортны җитештерә алабыз. Аны патруль яки ял итү өчен тәгаенләргә була. Зуррагын да төзергә мөмкин. Мәсәлән, 10 машина сыярлык паром формасында. Яшел Үзән һәм Югары Ослан дагы кичүләр өчен бик әйбәт булыр иде ул.



«Суатлар моделен Кабан күлендә сынадык», – ди Надир Баһавиев.

Ә планнарга килгәндә, башта индустрия өчен кечкенә, 600х600х1200 мм зурлыгында принтерлар ясау планлаштырыла. Алар ярдәмендә төзү еш очрый торган бакыр, корыч, алюминий, титан кебек металларны кулланырга ярдәм итәр иде. Кечкенә принтер уңышлы гына индустриягә кергәч, Хан-принтер төзү эшенә керешергә кирәк дип уйлыйм. Аның биеклеге 30 метр һәм диаметры 15 метр булыр дип күзаллана. Андый зур принтерда орбиталь ракеталар, самолетлар, суднолар һәм машиналар төзергә мөмкин.

Хан-принтер төзелгәч, беренче чиратта бюро бер баскычлы, күпкулланышлы орбиталь ракета төзи башлар дип уйлыйм. Бүген космонавтика өлкәсендә иң зур проблема ул – ракеталарны күпкулланышлы итү. Зур пассажир самолеты һәм орбиталь ракета бәясе бер чама, аларның һәркайсы якынча 50 миллион доллар тора. Тик самолетлар ун мең тапкыр кулланыла, ә ракета бер тапкыр гына. Шуңа күрә космоска очу егерме миллион доллар тирәсе тора, ә самолетта очу, гадәттә, мең доллардан да кыйммәтрәк түгел. Зур принтерда бастырылган ракеталар гади ысул белән төзелгәннәреннән күпкә җиңелрәк була, шуңа күрә аларны күпкулланышлы, бер баскычлы итеп төзергә мөмкин.

Татар конструкторлар бюросын төзергә этәргән тагын бер уй – андагы эшчәнлекне татар телендә алып бару. Бу гамәл телебезне фән һәм инженерлык үсешендә куллану дәрәҗәсенә китерәчәк.

:: Планнар, гади кеше күзлегеннән карaганда, колач җитмәслек һәм вакыты белән фантастика кебек тә тоела. Теләктәшләрегез бармы?

– Инженерлар, конструкторлар, төзүчеләр бик кызыксына. Бездә «акыллыбаш»лар, чыннан да, бик күп бит. Әлегә без кечкенәрәк контрактлар эзләү белән мәшгуль. Ә зурраклары өчен бюджет кирәк. Шуңа күрә дә, формасын уйлап бетереп, Татар конструкторлар бюросын тизрәк рәсмиләштерәсе иде. Ул дәүләтнеке була яки дәүләт һәм эшмәкәрләр партнерлыгы итеп оештырыла ала.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Яшьләр мәйданы

Акмаса да тама

Стипендия – әти-әни биргән, эшләп тапкан акча янына бер дигән керем чыганагы ул. Баксаң, уку йортыннан бирелә торган әлеге матди «күчтәнәч»кә «бюджет»та укучылар гына түгел, түләүле бүлектә белем алучылар да өметләнә ала икән. Студентка, академик стипендиядән тыш, тагын нindiләре каралган?

Югары стипендия (ПГАС). Студент уку йортының фәнни-тикшеренү, иҗтимагый, мәдәни, спорт тормышында активлык күрсәтсә, ул уку йортының югары академик стипендиясенә өметләнә ала. Акчаны кемгә өләшәсен вуз хәл итә. Шунысы бар: әлеге стипендия вузның барлык курсларында һәм факультетларында бюджет нигезендә укучыларның 10 процентына гына эләгәчәк. Ничә сум түлисен дә уку йорты үзе хәл итә. Гадәттә, вуз сайтларында бу хакта мәгълүмат урнаштырыла.

Социаль стипендия. Бу төр стипендия ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган ятим балаларга түләнә. Моннан тыш уку чорында ата-анасын югалткан студентлар да социаль стипендия алырга мөмкин. I һәм II төркем инвалидларга, ветераннарга, балачактан ук инвалид булган студентларга да социаль стипендия түләнә. Матди ярдәмне алу өчен деканатка документлар тапшыру кирәк. Ничә сум түлисен вуз хәл итә.

Югары социаль стипендия. Социаль стипендия алучы һәм 1 һәм 2 нче курс студентлары сессиясен «яхшы» һәм «бик яхшы» билгеләренә генә япкан студентлар мондый төр стипендия алырга хокуклы. Моннан тыш бу стипендия 20 яшькә кадәр булган, әтисе йә әнисе белән генә яшәүче һәм I группа инвалид саналган студентка да эләгәчәк. Шунысы да бар: бу очракта сессиянең нинди билгеләргә ябылуына әһәмият бирмиләр. Мондый стипендиянең күләме яшәү минимумыннан ким булырга тиеш түгел.

Дәүләттән бүләк. Түләүле бүлектәгеләргә дә, «бюджет»тагыларга да кагыла торган матди ярдәм төрләре бар. Мәсәлән, Россия Хөкүмәте стипендиясе. Аны вузның 1 нче курсы студентларына бирәләр. Шартлары мондыйрак: студент БДИда 80 баллдан югарырак күрсәткечкә ия (профильле предметтан), олимпиадаларда призлы урын алган яисә җиңүче булырга тиеш. Мондый төр стипендиянең күләме – ай саен 5 мең сум.

Татарстан Рәисе стипендиясе дә бар. Олимпиадада призлы урын алган яисә БДИда 100 балл җыйган 1 нче курс студентларына бирелә ул. Күләме – ай саен 7 мең сум. Казан мэрының да махсус стипендиясе бар.

Вузларны күзәт. Моннан тыш, еш кына югары уку йортларында үзләренең махсус стипендияләре була. Әйтик, КГЭУ, КФУ еш кына студентларын шулай куандыра. Өстәмә мәгълүматны вуз сайтларында, деканатта һәм профкомда белешергә мөмкин.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ru.freepik

Караңгы дип зарланганчы...

Соңгы вакытта күбебез миллилек югала, үз-үзебезне югалтабыз, милли горурлыгыбыз кимеде, дип борчыла. Һәм, ни кызганыч, бу проблемаларның көннән-көн артуын таныган хәлдә, без кемнәрне яки нәрсәне генә гаепләмибез. Җитәкчеләрне, системаны, заманны... Тик үзебезне генә түгел. Караңгы дип зарланганчы, бер булса да шырпы кабызырга кирәклекне онытабыз.

Балтач марилары, удмуртлары исә – бу яктан башкаларга менә дигән үрнәк. Алар зарланып утырмый, мөмкин булган һәр урында милли үрнәкләргә өстенлек бирә. Авылларда, мәдәният йортларында милли бәйрәм-йолаларын оештырып кына калмый, аларны рәсми чараларда да башкаларга бик теләп күрсәтә. Төгәлрәге, куллана. Берсе икенчесенә комачауламый, берсен берсе тулыландыра гына, дип саный алар. Әлегәчә беркемнән дә ник алай эшлисез, эшләмәгез, дигән кисәтү булганы юк. Мөгаен, һәр эшкә тәвәккәллек һәм теләк, ният кирәктер.

Соңгы елларда социаль челтәрләрдә Балтач ЗАГСына милли киемнәрдән килгән удмуртлар, мариларны, аларның үз йолаларын үтәүне күрсәткән видеоларны еш күрергә була.

– Мин Балтач ЗАГС бүлегендә унбиш ел җитәкче булып эшлим, шушы чорда барлык удмурт-мариларны язылыштыру тәртибе үзгәрмәде. Бары тик катнаш гаиләләр булганда гына бу өлеше төшеп калырга мөмкин, – ди «Бу яңалык кайчаннан гадәти күренешкә әйләнде?» дигән соравыма Зөһрә Әхмәтханова. – Бу һич тә яңалык түгел. Буыннан-буынга дәвам иткән, бүгенгәчә өзелмәгән, инде бер матур традициягә әйләнгән. Моңа кадәр җәмәгатьчелеккә таралмавының сере шунда гына: элек язылышу тантаналары авыл Советларында үтә иде. Шул чорда ук алар рәсми чара белән милли йолаларны бик матур итеп, бергә башкарган. Хәзер теркәү өлеше район үзәгендә булгач, бу гадәтләре турында барыбызга да мәгълүм булды. Марилар, удмуртлар язылышканны белми-күрми калып булмый, алар язылышу тантанасы үтә торган мәдәният йорты каршында ук җырлы-биюле йолаларын башлап, бөтен кешенең игътибарын җәлеп итә. Рәсми өлеш беткәннән соң, үзебез дә һәр очракта яңа күргән кебек сокланып күзәтәбез. Марилар исә безгә килгәнче үк, авыл урамын әйләнеп, туйны бөтен авыл бәйрәменә әйләндерә. Язылыштыру вакытында алар бер генә йола үтәми, анда өлкәннәр дә, яшьләр дә, балалар да катнаша. Менә шушы буыннар арасында бәйлелек өзелмәгәнгә, милли йолалар онытылмый, дәвам итә, сакланадыр да инде. Беләсезме, алар бу чараны шулкадәр ихластан, шулкадәр зур әзерлек белән үткәрә: милләтең белән горурлык хисләре уяна торган. Безгә башка елларны күрше райондагы мари авылыннан да килеп, шушы тәртиптә язылышалар иде. Быел үзебезнекеләр генә.

– Татарлар, башка милләтләр арасында ЗАГСка милли киемнән килүчеләр бармы?

– Кызганыч, юк шул...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ЧИТКӘ КИТҮ – ГАСЫР ЧИРЕ

Вазгыять

Республиканың акыллы башлары читкә китеп бетмиме? Ел саен август аенда күтәрелә торган четерекле тема бу. БДИда югары балл туплаган, бәйгеләрдә җиңгән уку алдынгыларын үзебездә калдыру өчен нинди кызыксындыру чаралары бар? Вузларда соңгы нәтиҗәләр игълан ителгән көннәрдә шул хакта белештек.

Түбән Камадагы 35 нче лицейны тәмамлаучыларның яртысы ел саен Мәскәү, Санкт-Петербург вузларына укырга керә. Быел да сан шул тирә булыр, дип фаразлыйлар. Лицейны барлыгы 108 егет һәм кыз тәмамлаган. Шулар арасында БДИда ике фәннән 100әр балл туплаган Тимур Москвин да бар. Ул Питерда табиб белгечлеген үзләштерәчәк. 11 бюджет урынының берсе нәкъ менә аңа тәтегән икән. Лицейда биш укучы 100 балл җыйган.

– Әлегә вузларда рәсми боерыклар чыкмады. Укучыларның кая китүләре турында мәгълүмат җыябыз, – диде лицей директоры Чулпан Хуҗанбердиева. – Яшьләрнең читкә китүе – гасыр проблемасы. Безнең укучылар көндәшлеккә сәләтле мохиттә укый. Аларны ишегалдындагы гадәти уку йорты канәгатьләндерми. Яхшы мәктәптә белем алып, имтиханнарны яхшы балларга бирәселәре килә. Без 5 нче сыйныфка кабул итәбез. Химия, биология, математика фәннәрен тирәнтен укытабыз. Иң әйбәтләр арасында укып, көндәшлеккә өйрәнгән укучыларга яхшы вузлар кирәк, әлбәттә. Иң мөһиме – ярышырга кеше булсын. Өстерәлеп баручылар белән уку кызык түгел. Безнең вузларда хәрби кафедра, тулай торак бар, әмма бу яшьләрне җәлеп итми. Яшерен-батырын түгел, абитуриент җитми дип, кайберләре яхшы укыганнарның барысын да алырга тырыша. Әлбәттә, бу бездә начар дигән сүз түгел. Безнекеләргә чын көндәшләр кирәк. Уку алдынгыларыбыз КФУ, КДМУ ректорлары белән дә очрашты. Әллә кем булып кыланып, бармыйча калмадылар. «Йолдыз» чире юк аларда.

Быел Казанның 131 нче лицеен тәмамлаган Майя Дробышеваның да читкә китү теләге булган. Әмма ул КФУда программист белгечлеген сайлаган.

– Олимпиада нәтиҗәсе буенча Санкт-Петербург вузына керү мөмкинлегем бар иде. Әмма минем яраткан шәһәрем Казанда каласым килде. Читтәге кояшка кызыкмадым. Үзебездә дә ким укытмыйлар. Өстәвенә КФУда мин сайлаган юнәлеш иң яхшылар арасында санала. Бу минем өчен бик мөһим. Имтиханнардан барлыгы 250 балл җыйдым. Олимпиада өчен тагын 24 балл өстәделәр, – диде Майя Дробышева.

Шәһәр генә түгел, авыл балалары да укуда калышмый. Әнә Саба районының Тимершык мәктәбен быел алты укучы тәмамласа, шуларның икесе (!) 100 балл җыйган. Баязит Дәүләтов – тарих, Айлия Хаҗиева рус теле сынавында иң югары нәтиҗәгә ирешкән. Сыйныф җитәкчесе, рус теле укытучысы Гөлфинә Вәлиева белдергәнчә, икесе дә читкә китү турында уйламаган. Исәпләре – КФУның юридик факультетына укырга керү. Имтихан баллары югары. Исемлектә 1–2 урында торалар.

– Безнең мәктәп өчен бик зур горурлык бу. Моңа кадәр 100 балл җыючылар булмады. Дөрес, 98 балл туплаучылар бар иде. Быелгы ике укучы тырыш, максатчан. Айлия 7 нче сыйныфтан бирле рус теле һәм әдәбиятыннан олимпиадаларда призер һәм җиңүче булды. Баязит тарихтан олимпиаданың Россия этабында катнашты. Күп фәннәрдән район, республика бәйгеләрендә урыннар яулады, – ди 28 ел рус теле укытучы Гөлфинә Вәлиева.

Саба районының мәгариф бүлеге башлыгы Илфат Шакиров әйтүенчә, район мәктәпләрен тәмамлаучы чыгарылыш укучыларының күбесе республика вузларын сайлый. КФУ, КАИ, КХТИга укырга керәләр. Читкә китүчеләр бик аз. Быел 4 укучы БДИдан 100 балл туплаган. Барысы да Татарстанда калачак.

– Читкә китү гаеп эш түгел. Анда уку тагын да отышлырак. Яшьләр яңалыкка омтыла, дөньяны икенче күзлектән күрергә өйрәнә. Укып бетергәч, үзебезгә кайтып эшлиләр икән, файдалары күбрәк булыр дип уйлыйм. Кайтмасалар да, барыбер илебезгә хезмәт итә бит. Читкә үк чыгып китмиләр, – ди Илфат Шакиров.

Аның әйтүенчә, читкә БДИны яхшы биргәннәр, иң белемлеләре китә. Әмма бу уку сыйфаты аерыла дигән сүз түгел. Әйтик, Санкт-Петербург белән чагыштырганда, Казан дәүләт медицина университетына укырга керү өчен югарырак баллар кирәк. Керә алмаганнары башка төбәкләрдәге вузларга китә. «Үзебезнең университетлар заманча лаборатория, башка җиһазлар белән тәэмин ителгән. Безнең вузлар өстенрәк дип уйлыйм», – ди ул.

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының матбугат җитәкчесе Алсу Мөхәммәтова белдергәнчә, ел саен август аенда йөз балл алучыга министрлык аша акча түләнә: бер фәннән – 15 мең, ике фәннән – 25 мең сум. Яшьләрне җәлеп итү өчен, вузлар үзләре дә кызыксындыру чаралары уйлап таба. Моны һәркайсы үзе хәл итә.

КФУдагы мөмкинлекләргә кызыгырлык та шул. Анда бер фәннән 100 баллга – 100 мең, ике фәннән 200 баллга – 200 мең, өч фәннән 300 баллга 300 мең сум түләргә вәгъдә итәләр. Башка вузларга да яхшы баллы абитуриентлар кадерле. Әйтик, КХТИда БДИдан 240–259 балл җыйган студентлар – айга 6600 сум, 260–279 баллы студентлар исә 8800 сум алырга мөмкин. Олимпиада җиңүчеләре һәм призерларына, шулай ук сынауда 280нән югары балл туплаучыларга 15 мең сум түләнә. Казан дәүләт энергетика университетында, балл күләменә карап, өч семестр дәвамында 5тән 16 мең сумга кадәр акча бирмәкчеләр. Димәк, тырышып укыганнарны үзебездә дә бәялиләр. Тик һәрбер студент үз юлын үзе сайлый.

Сәрия МИФТАХОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

Комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау авыл җирлегендә урнашкан күчемсез милек объектларына карата (кадастр кварталы номеры 16:16:083201) 06.03.2023 № 923000033-ОК дәүләт контракты нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау авылы, Юбилей урамы, 1А й., 1000 бүлмә (телефон: +7 (84365) 74-7-79) яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы администрациясенең (vysokaya-gora.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең (rosreestr.tatarstan.ru.) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 1 сентябрендә (11 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау авылы, Юбилей урамы, 1А й., 1000 бүлмә.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 9 августыннан 2023 елның 1 сентябренә кадәр һәм 2023 елның 1 сентябреннән 2023 елның 7 октябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Тәфсилле мәгълүматлар сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Әгъза

Мине аптырауга калдырган нәрсәләр күп инде ул. Тик шуларның иң еш очрый торганы шушы бугай – кешеләрнең мине аңламавы… Менә болай дисәң, бөтенләй бүтән төрле ишетелә әле ул: «Аһ, мине беркем дә аңламый, мин ялгыз, кирәксез…» – дип зар елаган сыман. Алай түгел. Кешеләрнең мине дөрес аңламавы, дияргә кирәктер. Мин бер төрле әйтәм, алар я бөтенләй аңламый, я бүтән төрле аңлый. Мин әйткәнне нәкъ мин әйткәнчә аңлаучылар сирәк. Сүз менә шул хакта бара.

Мондый очраклар үзара сөйләшкәндә дә, сәхнәләрдән чыгыш ясаганда да, хәтта әдәби әсәрләрне кабул итүдә дә чагыла. Соңгысы бигрәк ачуны чыгара торган. Соң, язылган, ташка басылган бит инде, укы, аңламасаң, тагы бер кат укы, аңлаганчы укы – барысы да синең ихтыярда. Юк, алай итмиләр, үзләре аңлаганча кабул итәләр дә соңыннан: «Марат шулай язган», – дип, мине гаепләп йөриләр. Юк, яп-яланаяк, мин алай дип язмадым, аны син шулай кабул иттең. Син аны мин язганча да кабул итә ала идең, тик син аны үзең булдыра алганча, үзең язарга теләгәнчә, үзең кабул итә алганча… Баштарак мин шулай үртәлә торган идем. Хәзер аңладым инде. Аның сәбәбе бик гади икән.

Менә сез кулсыз кешене күз алдына китерә аласызмы? Менә шул кеше дә башкалар белән табынга утыра, син барысы алдына да бердәй итеп тәмле-татлы ризыклар куясың. Барысы да ашый, торып китә. Барысының да тамагы тук була. Теге ике кулсыз кешедән башка. Ул ач кала. «Ашатмадылар мине», – дияргә дә мөмкин. Син аптырыйсың: «Нишләп ашатмыйм ди, барыгызга да тигез өләштем бит!» Син дә хаклы, теге кеше дә хаклы. Чөнки ул ашасын өчен, алдына кую гына җитми, авызына каптырырга кирәк. Чөнки аның куллары юк.

Берни ишетми торган саңгырау кешеләр була. Син бик талантлы музыкант, бик искиткеч җырчы булып аның алдында төннәр буе уйнарга, җырларга мөмкинсең. Ул күрә синең уйнаганыңны, җырлаганыңны күрә. Тик ул синең моңыңны ишетми. Ул шушы мизгелдә үз күңелендә кузгалган моңны тыңлый. Сиңа ни генә дип әйтсә дә, ничек кенә бәһаләсә дә, ул үз күңелендәге моңны бәяли. Яки моңсызлыкны. Сез икегез ике яссылыкта, ул сине ишетми. Чөнки аның колагы ишетми.

Күзе күрми торган кешеләр була… Әгәр ягымлылыгың, әйбәтлегең, тагын нindидер сыйфатларың белән аңа ошый аласың икән, хәтта маймылдан да ямьсезрәк булсаң да, син аңа матур булып күренәсең. Чөнки синең чын йөзеңне күрми, ул үзенең сиңа мөнәсәбәтен күрә.

Синең әйткән фикереңне аңлый алмаучылар булуы да – шундый ук табигый хәл. Алар сине беркайчан да аңлый алмый, чөнки аларның синең фикереңне аңлый ала торган әгъзасы юк. Яки булып та, тиешле дәрәҗәдә эшләми. Бу очракта инде бераз аңлыйлар, ләкин син әйткәнчә, син теләгәнчә түгел, ә үзләре кабул итә алганча. Бу гаеп тә, гариплек тә түгелдер инде. Табигый хәлдер.

Коммунизм чорында бигрәк көчле сизелде, ул заманда «Бөтен кеше дә бертигез» дигән фикер лозунг урынына яңгырап торды. Тик бөтен кешенең дә бертигез икәнен ассызыклау җәмгыятьнең башка формалары өчен дә хас. Шул ук демократия, мәсәлән: сайлаулар нигезендә кешеләрнең тигезлеге ята – депутатны сайлау өчен бөтен кешенең дә тавышы бертигез дәрәҗәдә бәяләнә.

Ләкин кешеләр бертигез түгел. Моны исбатлаган галимнәр фикерен китереп тормыйм, сез аны үзегез дә һәр адымда күрәсез. Күзегез булса, әлбәттә. Хәтта бер үк гаиләдә туып, бер үк тәрбия алып үскән балалар да әллә ничә төрле була. Хәтта бер-берсенә тамчы судай охшаган игезәкләрнең дә характеры ут белән су сыман аерыла ала. Организм үзенчәлекләреннән тора барысы да.

Ә кешенең организмы гади күзгә күренә торган әгъзалар белән генә чикләнми икән. Аяк-кул, баш һәм башкалар гына түгел. Баш миендәге күзәнәкләрнең бик күп төрле гамәлләр белән идарә итә торганнары да була икән. Кичерешләр белән, мәсәлән. Берәү авыртуны нык интегеп үткәрә, ә икенче кеше сизми дә, чөнки аның моны тоя торган күзәнәге юк. Яки берәү мәхәббәт хисеннән башын җуярга мөмкин, ә икенче адәм бөтенләй ярата белми, алай гына да түгел, ул башкаларның «ярату» дип өзгәләнүен дә аңлый алмый, чөнки андый тойгылар эшчәнлеген хасил итүче күзәнәге юк. Фикер йөртү сәләте дә төрле кешедә төрлечә була: берәүнеке балта түтәсе кебек тупыйк, беркая да үтеп керәлми, кая юнәлтсәң дә дыкылдап тик тора, икенчесенеке балта йөзендәй үткен, ә өченчесенеке бөтенләй юк – балтасыз саплык кебек. Бу гаеп тә, кимчелек тә түгел, бары тик үзенчәлек кенә. Бер кешене дә: «Нигә син ямьсез! Нигә син көчсез!» – дип тиргәп тә, гаепләп тә булмый бит инде. «Нигә син матур, нигә көчле?!» – дип тә тиргәп булмый. Килешергә генә кала.

Кыскасы… Әгәр сине аңламыйлар яки дөрес аңламыйлар икән, моңа үртәлергә ярамый. Гаепләргә дә кирәкми. Сөенергә генә кирәк – ярый әле мин дә шундый түгелмен, дип. Чөнки аларның сине аңлый ала торган әгъзасы юк яки тиешенчә эшләми. Ике кулсыз кешенең сине кочаклап алмавына үпкәләп булмый бит инде. Монда да шундыйрак хәл. Бары тик күзгә бәрелеп кенә тормый.

Сез мине аңладыгызмы?

ҮТКӘННӘР САГЫНДЫРА(МЫ)?



«Татар-информ»

Кайтаваз

Салават Фәтхетдинов концертында Ядкәргә эш табылмаган! Аның каравы, төркемгә уйный торган музыкантлар эзлиләр, ди! Ә калганы… Калганы үзгәрешсез. Үзгәртергә тырышсалар да, Салават үзгәрмәде.

Казанда Татарстанның һәм Башкортстанның халык, Россиянең атказанган артисты Салават Фәтхетдинов концертлары гөрли. Тамашачы күп булу сәбәпле, елдагыча, өстәмә концерт та куячак сәхнә мэтры. 35 нче сезон концертына җыелган тамашачы арасында «ВТ» хәбәрчесе дә булды.

Салават мөгез чыгарам дип тырышмаган. Сәхнә дә гади, җырлар да гади иде. Чыбыклы микрофон, ак пәрдәле сәхнә (элек иң затлы залларда гына була торганы!), баянчыларга кушылып җырлаулар… Кешегә шоу-тамаша түгел, таныш көйләргә кушылып, хатирәләрне яңарту кирәк дип тапканнар бу юлы. Дөрес фикер. Хәзер элеккеләрнең тузанын кагып, аны яңарту модада. Ихласлык җитмәгән, декорация белән тулган дөньядан арып, аңа килә бит тамашачысы. Хатирәләрне яңарту җырчының үзенә дә кирәк булгандыр. Ни дисәң дә, Салаватка инде 63 яшь бит! Яшенә бәйле рәвештә шаяртулар да булды. Анысы турында соңрак.

– Микрофон чыбыгын шулай селтәп йөрмәгәнгә күпме вакыт узды инде. Сул кулга гел нидер җитми төсле. Без бу юлы гади тамаша уйлап таптык. Ничек башлаган булсак, шуңа әйләнеп кайттык, – диде җырчы, быелгы тамашасының асылын аңлатып. Бераз алгарак китеп әйтик: ялт-йолт утлар да кирәкми, сәхнәгә төтен дә җибәрәсе килми, кыйммәтле зур экраннар да куймыйбыз, дисә дә, соңрак Салават замана таләбенә баш иде булса кирәк. Утлар да булды, экранны да күрдек. Экранда исә – магнитофон. Күпләрне Салават иҗаты белән тәүге тапкыр таныштырган җайланма инде монысы. Экран үткәннәрне искә төшерер өчен дә ярап куйды: Салаватның, аның төркеменең яшьлеген фотосурәтләр аша күзәттек.

Концерт хитлардан гына торачак, дип кисәткән иде җырчы алдан ук. Шулай булды да. Концертта нибары 4 яңа җыр яңгырады. Аларны бер-бер артлы башкаргач, әллә яңа, әллә юк – халык отып та өлгермәде бугай. Ярар, киләсе концертларда алары хит булып яңгырый башлагач, отарбыз әле. Салават җырлаган җырның халык теленә керми калганы юктыр.

Концертта буыннар бәрелеше, ягъни «аталар һәм балалар» темасы да кузгатылмады түгел. Моны алып баручы вазыйфаларын башкарган Ядкәр Хәбибуллин һәм Алмаз Муллаянов дуэтында күрергә мөмкин иде. Әйтик, Алмаз «болай итик, тегеләй итик, Салаватны үзгәртик, шаблон буенча бармыйк» дип тырышып маташса, җырчының тугры Ядкәре: «Салават Салават булып калырга тиеш!» – дип каршы төшә. Халык та моны куәтли.

Укучыларының чыгышлары белән чиратлашып (бу да – традицион күренеш), Салават концерты бер дулкында дәвам итте. Ара-тирә җырчы шаяртты, истәлекләрен сөйләде. Шаяртулар исә хатын-кыз мантыйгы, ир һәм хатын-кыз арасындагы мөнәсәбәт, буыннар бәйләнеше, эстрада торышы, заманага бәйле иде. Бу яшьтә тагын нәрсә хакында шаяртасың инде?

«1990 нчы еллар, концертларда кызлар сәхнәгә менә. «Яратам», – диләр инде. Еллар үтте, яшь кызлар менә дә: «Сезне минем әни шундый ярата!» – диләр. Аннан тагын да яшьрәк кызлар менеп: «Сезне минем әби шундый ярата!» – ди. Өч чор яшәлгән шулай».
«Хатын-кыз, дибез. Хатын-кызны аңлау бик авыр. Хатын-кызны аңлаган кешене дә күргәнем юк. Кайвакыт алар үз-үзләрен дә аңламый. Хатын-кызга «юк» дигәнче, «әйе» дип котылуың яхшырак. Ә үз фикереңне аңа аңлату, гомумән, мөмкин түгел!»
«Мин болай дип уйлыйм: хатын-кызны аңларга кирәкми. Аны яратырга кирәк. Ә ирләрне аңларга. Яратучысы табылыр…»

Мәзәкләрнең тозсызы да яңгырады. Кемгә ничек – андый мәзәк ишетү (бигрәк тә Салават концертында, академия театры сәхнәсендә!) күңелгә май булып ятмады шул. Әмма халык көлде. Көлгәч, ошатканнардыр, димәк.

Әйтик, Салават концертларының берсендә аңа чәчәк бирергә бер ханым менә. Бу хатын-кыз, җырчыны кочаклап: «Картая белмәдең инде, с…ка!» – дип «шелтәләмәсенме»! Салаватның гаять бай иҗади карьерасында халыкка чыгып сөйләрдәй башка истәлекле вакыйга калмаганмы икән, дигән уй керде шуннан соң. Салаваттан инде «әдәби сүз» генә түгел, мәгънәле, аксакал сүзе дә ишетәсе килә бит.

Йә булмаса төрле яшьтәге җырчыларның физиологик мөмкинлекләрен тикшерү турында мәзәк урынлы булдымы икән? Укучы үзе хәл итсен әле, без әйтмәдек, яме?

«Күп кенә җырларның йә көе сүзләренә туры килми, йә сүзләре мәгънәсез була. Мәсәлән, Рөстәм Закиров: «Яннарымда булгалап кит, көнгә 5 кенә минут», – дип җырлый. Нишләп була соң ул 5 минутта? Хәер, олы кешегә 5 минут җитәдер.
Шул ук темага Зөлфия Шакирова җырлый. «Мин бәхетле дияр өчен, миңа 5 минут җитә». Җәвитне дә, Зөлфияне дә бик яхшы беләм. Зөлфия дә алдаша белми. Зөлфиянең ни өчен бу җырны репертуарына алганына болай дип фикер йөртәм: Җәвитнең мөмкинлекләреннән чыгып алынган җырдыр бу.
Ярар инде, болары – өлкәннәр. Рифат Зарипов бөтенләй «ике минут кына» дип җырлый! Аның авырлыгына карагандa, 2 минут бик җиткәндер.
Әмма рекордсмен – Фирзәр Мортазин. Ул: «Бер генә минутка», – дип җырлый. Ә Фирзәр алдаша белми».

Әмма халык Салаватның һәр сүзенә, һәр мәзәгенә мөкиббән иде. Кем әйтмешли, Салават – халыкныкы, август – Салаватныкы инде ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

АФРИКАДА ТРАМВАЙ ЮК

Африка егете Эви Мавете, укыйм да кире туган ягыма кайтып китәм, дип килгән башкалага. Тик алты ел эчендә 29 яшьлек егет Казанны яратып өлгергән. «Беркая да китәсем килми, монда бик рәхәт», – ди ул. Ике ай элек 5 нче трамвайга йөртүче булып эшкә урнашкан. Үз илендә трамвайлар юк икән. Шуңа күрә әлеге транспортны иярләү бик кызык тоелган аңа.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясендә дүрт ел укыдым. Җан ияләрен бик яратам. Шуңа күрә эт-мәчеләрне дәвалап, игелек кыласы килгән иде. Тик «трамвай йөртүче кирәк» дигән белдерүне күргәч, барысы да үзгәрде. «Африкада трамвайлар юк бит, тукта, йөртергә өйрәним әле», – дидем. Ярты ел укыгач, ике ай элек эшкә урнаштым. Трамвайны зур горурлык белән йөртәм, – ди ул.

Вузга килешү нигезендә укырга керсә дә, кире кайтмаганы өчен Ватаны – Конго Республикасында аңа шелтә белдермәгәннәр. Укыган өчен акчаны да түләтмәгәннәр. Егетнең Татарстанда үз урынын табуына сөенгәннәр генә. Башкалага КФУда белем алучы ерак туганы Җдунор Камаландуа чакырган аны. Эви монда калса, ул Франциягә күченгән. Казанның студентлар шәһәре икәнен Африкада да яхшы беләләр икән.

Казанга килгәч, рус телен белмәү аркасында кыенлыклар шактый килеп чыккан. Вузда бер ел әзерлек төркеменә йөреп, телне өйрәнгән. Ә инде ике-өч ел дигәндә, үзе машина йөртеп, Татарстан буенча сәяхәткә кузгалган. Болгарны, Зөя шәһәрчеген, төрле тарихи урыннарны барып күргән. Театрларга, киного да йөрергә ярата ул. Мәдәният белән күбрәк танышкан саен, республиканы ярату хисе дә арткан. Студент вакытта курсташларына ияреп, авылга да кайткалаган. Татар милли ашларыннан авыз иткән. Барысы да ошаган аңа.

Эви татарча да бераз сукалый. «Исәнмесез, татарлар», «Казанны бик яратам», – дип тә әйтеп күрсәтте. Дәү әти, дәү әни, ипи, тоз… Өйрәнгән сүзләрен дә санап китте.

Сүз иярә сүз чыккач: «Татар кызына өйләнер идеңме?» – дип тә сорадык.

– Татарстанда яшим бит, ә нигә өйләнмәскә? Бу – бер вариант, – дип елмайды ул.

Казанга беренче тапкыр килгәч, иң беренче гаҗәпләндергән нәрсә әлеге дә баягы шул трамвай булган. Башкасы үзебездә дә бар, ди. Африка белән Татарстан арасында әллә ни аерма күрми. Шул ук машина, өйләр… Башта безнең табигатькә, салкыннарга ияләшә алмый интеккән. Кар күргәне бармыни? Беренче тапкыр урамнан туңып кайткач, кайнар су белән юынган. Тик дуслары, болай эшләргә ярамый, дип кисәткән. Җылы киемнәр сатып алган. Шуннан соң безнең кагыйдәләр буенча яши башлый. Кышын шугалакка бармыйча калмый.

Шәһәр халкының мөнәсәбәте турында да сораштык. Әлбәттә, ерактан килгән егеткә баштарак төбәлгән чит карашларны кабул итү җиңел булмый. «Әйдә бергәләп фотога төшик әле», – дип тә аптыратканнар. Трамвай кабинасында ак футболкалы, озын буйлы, кап-кара тәнле Эвины күргәч тә гаҗәпләнгәннәр, әлбәттә. Караңгыда исә тагын да шүрләтә. Ак футболкасы гына эленеп торган кебек тоела. Пассажирлар аны тиз арада үз иткән, хәтта кул биреп күрешә башлаган. Халыкның төрлесе бар. Әмма күбесе хөрмәт белән карый, ди.

Көнгә 8–12 сәгать эшләгән чаклары да була аның. Графигы төрлечә. Кайчак биш көн эшләп, бер көн ял итә. Хезмәт хакы әлегә – 35–40 мең тирәсе. Бу акча гына җитмәгәч, таксига да чыккалый, заказга ризыклар да илткәли. «Арымыйм, мин яшь бит әле. Эшемне җиренә җиткереп башкарырга тырышам. Вакыт тигәндә, баскетбол, бильярд уйныйм, дуслар белән аралашам», – ди Эви Мавете.

Тырышып җыйган акчасына тулай торактан бүлмә сатып алган. Әмма коронавирус вакытында, вазгыять авыр дип, сатарга туры килгән. «Бу – минем зур хатам», – ди Эви, үкенеп. Хәзер фатир арендаларга туры килә. Әле бик сөенечле көннәре. Улы янына кунакка әнисе килгән икән. Егет үзе исә туган ягына елга бер генә мәртәбә кайта.

Сәрия МИФТАХОВА

Соклану

Гомер заяга узмасын

«Татар хатын-кызы нинди булырга тиеш?» – дисәләр, бер дә икеләнмичә, Эльмира кебек, дияр идем. Аның килеш-килбәте, киенүе, үз-үзен тотышы, кешеләр белән аралашуы милләтнең асылын ача да бирә.

Эльмира Камалиева социаль челтәрләрдә үз блогын да алып бара. Язылучыларына бик игътибарлы, мөлаем. Эльмирага кешелекле булу, башкаларны хөрмәт итү сыйфаты кечкенәдән сеңгән. Әтиләре 42 яшендә вафат булганда, олы балага – 17, уртанчыга – 14 яшь, кечкенәсенә 6 ай була. Әнисе Тәнзилә шушы өч баласы белән тол калып, бар гомерен аларга багышлый. Иң мөһиме – аларны дөрес тәрбияли.

– Ирем белән күрше авыллардан без. Бер мәктәптә укыдык. Беренче күргәндә үк аның пөхтә булуына игътибар иткән идем. Аннары дуслашып киттек, – ди Эльмира. – Иремнең әти-әнисен бик яраттым. Әбием дә, алар рөхсәтеннән башка әниең янына барма, сорамыйча берни эшләмә, дип торды. Дөрес әйткән! Яши-яши шуны да аңладым: гаиләдәге татулык бер-береңнең әти-әнисен хөрмәт итүдән тора. Алга таба да матур итеп яшәргә язсын.

Азат белән Эльмира өч бала үстерә. Икесе дә сабыр, бер-берен аңлап, юл биреп яшиләр. Күптән түгел Казандагы 10 ел яшәгән фатирларын калдырып, Арчага күченделәр.

– Казанда тормыш чаба да чаба. Иремнең дә эше иртән чыгып китеп, төнлә кайта торган иде. Балалар аны күрми дә иде кайчак. Ә бит аларны кечкенә вакытта дөрес итеп тәрбиялисе дә бар. Әти тәрбиясе бик кирәк. Шуларны уйладым да, Арчага күченик, дидем. Ирем дә күп вакытын өйдә уздыра хәзер. Авылга кайтып йөрергә дә бик җайлы. 17 минутта кайтып җитәбез, – ди Эльмира. – Күченү теләге туды да, йорт эзли башладык. Ике көн элек сатуга куелган йортка күз төште. Шуны алдык та. Монда безгә бик ошый. Шулкадәр тыныч, рәхәт. Иң мөһиме – «бөке»дә утырып, гомер заяга узмый. Буш вакытыбызны балаларга багышлыйбыз.

Эльмира бик оста пешерә. Үз әнисе дә, каенанасы да бик уңганнар. Баксаң, әти ягыннан әбисе оста куллы булган. Иртәнге дүрттә эшкә киткән ирен өчпочмак пешереп озаткан ул. Нәселе булдыклы Эльмираның. Үзе дә әбисе һәм әниләреннән калышмый. Заказга тортлар пешереп сата.

– Заказга пешерү – җаваплы эш. Бөтен тырышлыгыңны саласың, осталыгыңны җигәсең, соңыннан, ни әйтерләр икән дип, кайтаваз көтәсең. Көненә тугызар торт пешергән чакларым булды. Мин аларны төнлә әзерлим. Көндезге вакытның күбесен гаиләмә калдырам, – ди ул. – Торт пешергәч, иремә танышлары, син гел тәмле әйбер ашыйсың инде, дип әйтәләр икән. Ул да югалып калмый: «Әйе, хатыным торт пешергәндә, йомырка тәбәсе әзерләп ашыйм», – дигән. Безнең баллыга исебез китми, итле ризыклар яратабыз. Үзебезгә күбрәк бәлеш пешерәм.

Гаиләнең әле бик күңелле мәшәкатьле чагы. Йортларын тәртипкә китерәләр. Мунча төзиләр. Эльмира исә тәрәзә пәрдәләре теккән. Шул арада кунаклар да өзелми үзләреннән. Үзбәкстанда яшәүче әбисе дә кайтып киткән, дуслары да гел килеп тора.

– Хәзерге көнебезгә сөенеп, шөкер итеп яшибез. Иремнең әти-әнисенә дә рәхмәтлебез. Үз әнием дә, ни генә булмасын, ярдәм итәм, дип тора. Оныклар рәхәтләнеп җәйне әбибабайда уздыра, – ди Эльмира.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5129 данә
Гомуми тираж – 14057 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 313

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+